


1 октябрьдә 2016 елнын козге чакырылыш кампаниясе башланып китте. Быелнын 31нче декабренә кадәр кичектерvләре булмаган һәм хезмәттән азат ителмәгән гражданнар хәрби хезмәткә алына.
- Елына ике тапкыр журналистлар белән чакырылыш кампаниясе турында пресс-конференция vткәрәбез, - дип сvзен башлады Мордовия Хәрби комиссариаты комиссары Игорь Валерьевич Тихомиров.- Яз башы айларында Мордовиядә чакырылыш комиссияләренә 1200 кеше хәрби частьләргә жибәрелде. Бvген Мордовиядә барлыгы хәрби хезмәт vтәргә тиешлеләр саны 1000 кеше.       Ватан сакчылары Коры жир гаскәрләре, Хәрби дингез флоты, Һава-космик кочләре, Һава-десант гаскәрләрендә һәм башкаларында хезмәт итәләр. Хәрби хезмәткә чакырылучылар арасында ин популяр юнәлешләр булып Һава-десант кочләре, махсус торкемдәге гаскәрләр кала бирә. Мордовия ДОСААФында аерым әзерлек vтеп 3 тапкыр парашютта сикергән 25 стрелок-парашютист егет хезмәткә әзер инде, - ди очрашуда республиканын хәрби комиссары. Алар ВДВда хезмәт итәрләр.
Козге чакырылыш компаниясе яналыклары турында да сойләп китте Игорь Валерьевич. Беренчесе - Россиядә хезмәткә чакырылганнарнын электрон картасы (паспорты). Армиядә хезмәт итәргә бурычлы егетнен берничә ел буе электрон паспортка сәламәтлеге, белеме, кайсы комиссариатта кайчан каралганлыгы, закон бозу очраклары турында барлык мәгълvмат тупланып бара. Бу эш хәрби комиссариат, уку йортлары, миграция, сәламәтлек саклау идарәләре һәм башка кvп кенә органнарын уртак электрон жепләр белән бәйлиячәк. Запаста булганда сборларда да катнаша алырлар.
И.В.Тихомиров:
- Теперь в ходе осеннего призыва перед отправкой в войска каждый призывник получает персональную электронную карту со своими биометрическими данными, изготовленную на республиканском сборном пункте. Также карта содержит сведения о профессиональной подготовке и состоянии здоровье новобранца, другую полезную информацию. Персональная электронная карта предполагает замену бумажных удостоверяющих и учетных документов (удостоверение призывника, военный билет, учетно-послужная карточка, карточка офицера) одним электронным носителем. По мере прохождения военной службы карта будет дополняться новой информацией.
Икенче яналык. Хәрби хезмәткә чакырылучылар арасында топ игътибар урта һәм югары һонәри белем алганнарга юнәлтелә. Андыйларны 20 яшьтә хезмәткә чакырылса, әлеге яналык буенча, 2017нче елнын 1нче январеннан, техникумнарын тәмамлап диплом алгач кына хезмәткә чакырылырлар.

Мордовиядә контракт буенча хезмәткә сайлау пункты житәкчесе Виктор Владимирович Валенцов: “Контракт буенча хезмәт итәргә теләк белдерvчеләр кvбәя. Югары белем алган егетләребезнен кvбесе ике елга контракт нигезле хезмәтне сайлыйлар. Козге призывта шундый 22 гариза бар инде. Контракт хезмәтендәгеләргә тиешле социаль пакет исә офицерларныкы кебек vк. Алар фатир яки тулай торак белән тәэмин ителә”.
Шуннан житәкче нинди роталарда хезмәттә икәнлеге турында да әйтте: фәнни ротада (ГК ВКС) очәv: бер егет конкурслар vтеп, Красногорскта фәнни юнәлешендәге ротада хезмәт итә; шундый момкинчелек тә бар. Альтернатив хезмәттә бvген бер егет. Ардатово районы егете Северодвинск - 2 почта бvлегендә бер ел урынына оч ел хезмәт итәчәк.
Үзәк хәрби округ буенча хезмәткә яраклылар 76,0 %, Мордовиядә - 82,0%. Бу ин яхшы кvрсәткеч. Ин әйбәт язгы призывта Саранск шәһәре, Большеберезник, Ельник, Темник, Теньгушево, Ковылкино, Кочкурово районнарында vтте. 2016 елнын 20 октябрендә беренче хәрби хезмәткә озату булыр.
Качып йорvчеләр турында да сvз булды. «Уклонистлар»га килгәндә, елдан-ел андыйлар саны кими. Бирелә 27 яшь тулган “уклонист” егетләргә “кәжә билеты” яки кәгазь тапшыралар; vткән ел 44 справка биргәннәр. Аларнын эшкә урнашу момкинчелекләре чикле.
Жиде ел дәвамында “Әниенә шалтырат» дигән социаль проект эшли. Призывникка тvләvсез 3 һәм кvбрәк тә льготалы сим-карта бирелә. Менә шундый хәбәрләр ишеттерделәр пресс-конференциядә.
P.S. Хәрби чакырылыш буенча сораулары булганнар тvбәндәге номерлар буенча шалтырата ала:
385505 - Мордовия Хәрби комиссариатынын “кайнар линия”се;
88412545513 - Пенза Хәрби прокуратурасынын кайнар линия телефоны.

**Наилә Насырова**